**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"29" март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы «2024 елга гражданнарнын узара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Иске Мәңгәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә Муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Иске Мәңгәр торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

"2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү («Әбекэй» һәм «Ак үрдэк» чишмәләрен төзекләндерү (ремонтлау, чистарту, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

2) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру));

3) Торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү һәм чистарту (иске агачларны кисү, чистарту, сквер булдыру өчен яңа агачлар утырту,

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет Большеменгерского сельского поселения

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.